КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 27 март г.Казань № 353

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Чит кеше каравына мохтаҗ өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасында катнашучыларның ведомствоара хезмәттәшлеге регламентын раслау турында» 2021 ел, 17 ноябрь, 1098 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Чит кеше каравына мохтаҗ өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасында катнашучыларның ведомствоара хезмәттәшлеге регламентын раслау турында» 2021 ел, 17 ноябрь, 1098 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә татар текстында «Чит кеше каравына» сүзләрен «Карауга» сүзенә алмаштырырга;

беренче абзацта татар текстында «Чит кеше каравына» сүзләрен «Карауга» сүзенә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Чит кеше каравына мохтаҗ өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасында катнашучыларның ведомствоара хезмәттәшлеге регламентында:

исемендә татар текстында «Чит кеше каравына» сүзләрен «Карауга» сүзенә алмаштырырга;

1.1 – 1.3 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Бу Чит кеше каравына мохтаҗ өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасында катнашучыларның (алга таба шул ук эзлеклелектә – озак вакыт карау системасы, озак вакыт карау системасында катнашучылар) ведомствоара хезмәттәшлеге регламентында озак вакыт карау системасында катнашучыларның ведомствоара хезмәттәшлеге, шулай ук ведомствоара хезмәттәшлеге (мәгълүмати хезмәттәшлекне кертеп) формалары

тәртибен билгели.

1.2. Озак вакыт карау системасында катнашучыларның ведомствоара хезмәттәшлеге карауга мохтаҗ гражданнарны ачыклаганда һәм аларга озак вакыт карау буенча хезмәтләр күрсәтүне оештырганда гамәлгә ашырыла.

1.3. Озак вакыт карау системасы кысаларында ведомствоара хезмәттәшлектә катнашучылар:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы һәм шәһәр округларындагы социаль яклау идарәләре (бүлекләре) (алга таба – территориаль социаль яклау органы), Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү оешмалары (алга таба – социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре);

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, тиешле елга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә өлкән яшьтәге кешеләргә беренчел медицина-санитария һәм стационар медицина ярдәме күрсәтү өлешендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын гамәлгә ашыруда катнашучы барлык милек рәвешләрендәге медицина оешмалары (алга таба – медицина оешмалары);

төбәк координация үзәге (алга таба – координация үзәге) функцияләрен башкаручы «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Республика ресурс үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

«Татарстан Республикасы буенча Медик-социаль экспертиза баш бюросы» федераль казна учреждениесе, медик-социаль экспертиза федераль учреждениеләре;

Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге;

озак вакыт карау системасы кысаларында күрсәтелә торган социаль хезмәтләр күрсәтүгә ярдәм итүче ирекле (волонтерлык) оешмалар һәм волонтерлар;

II бүлек исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Озак вакыт карау системасында катнашучыларның карауга мохтаҗ гражданнарны ачыклау һәм озак вакыт карау системасына кертү буенча эшчәнлеген координацияләү»;

2.1 пунктта «чит кеше каравына» сүзләрен «карауга» сүзенә алмаштырырга;

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең карауга мохтаҗ гражданнарны ачыклау һәм озак вакыт карау системасына кертү буенча, социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең медицина оешмалары белән ведомствоара хезмәттәшлеге буенча эшчәнлеген координацияләү координация үзәге тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

3.1 пунктның беренче абзацында «чит кеше каравына» сүзләрен «карауга» сүзенә алмаштырырга;

14 пунктта «дәүләт учреждениесе – Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм

социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

IV бүлек исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IV. Карауга мохтаҗ гражданнарны ачыклаганда һәм аларны озак вакыт карау системасына керткәндә ведомствоара хезмәттәшлек тәртибе»;

4.1 һәм 4.2 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Карауга мохтаҗ гражданга өйдә медицина хезмәтләре күрсәткәндә йә карауга мохтаҗ гражданга стационар рәвештә медицина хезмәте күрсәткәндә карауга мохтаҗ граждан турындагы мәгълүмат түбәндәге срокларда карауга мохтаҗ гражданны ачыклаган медицина оешмасы тарафыннан гражданның яшәү урыны буенча өлкән яшьтәге кешеләргә беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүче медицина оешмасына тапшырыла:

өйдә медицина хезмәтләре күрсәткәндә медицина оешмасы тарафыннан ачыкланган көннән бер эш көне эчендә;

гражданны стационар медицина оешмасыннан чыгарган көнгә кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча.

4.2. Гражданның яшәү урыны буенча өлкән яшьтәге кешеләргә беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүче медицина оешмасы карауга мохтаҗ граждан мөрәҗәгать иткәндә, шулай ук бу оешмага өйдә яисә стационар формада медицина хезмәтләре күрсәткәндә мондый гражданны ачыклаган медицина оешмасыннан карауга мохтаҗ граждан турында мәгълүмат кергәндә, медицина тикшерүен, диспансеризация һәм диспансер күзәтүен уздырганда, участок табибы яки башка табиб карауга мохтаҗ гражданда булганда, диагностик тикшеренүләр һәм дәвалау процедуралары үткәргәндә карауга мохтаҗ граждан ачыкланган көннән бер эш көне эчендә карауга мохтаҗ граждан турындагы (аның хакында мәгълүмат керү хакында) мәгълүматны Халык социаль регистры аша карауга мохтаҗ гражданның яшәү урыны буенча территориаль социаль яклау органына тапшыра.»;

4.4 пунктта «Чит кеше каравына» сүзләрен «Карауга» сүзенә алмаштырырга;

V бүлек исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«V. Карауга мохтаҗ гражданның социаль хезмәт күрсәтүгә, шул исәптән карау буенча социаль хезмәтләр күрсәтүгә, карауга мохтаҗ гражданга озак вакыт карауның социаль пакетына кертелгән социаль хезмәтләрне сайлап алуда индивидуаль ихтыяҗларын билгеләгәндә ведомствоара хезмәттәшлек тәртибе һәм формалары»;

5.1 пунктта «Чит кеше каравына» сүзләрен «Карауга» сүзенә алмаштырырга;

5.2 пунктның «чит кеше каравына» сүзләрен «карауга» сүзенә алмаштырырга;

5.3 һәм 5.4 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Карауга мохтаҗ граждан турында мәгълүмат Халык социаль регистрына кергәндә координация үзәге:

карауга мохтаҗ граждан турында мәгълүмат алынган көннән ике эш көне эчендә координация үзәге белгечләренең – карауга мохтаҗ гражданны карауга мохтаҗлыкны бәяләү экспертларының өйдә булуын оештыра, аларның максаты – аңа социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе һәм шартлары турында мәгълүмат бирү, шулай ук аның тормыш эшчәнлеге шартларын тикшерү һәм карауга мохтаҗ гражданның социаль хезмәт күрсәтүгә, шул исәптән карау буенча социаль хезмәтләргә индивидуаль ихтыяҗларын билгеләү һәм карауга мохтаҗ граждан йә аның законлы вәкиле тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү турында гаризаны рәсмиләштергәндә

караугa мохтаҗлык дәрәҗәсен билгеләү;

караугa мохтаҗ граждан (аның законлы вәкиле) тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза бирелгән датадан дүрт эш көненнән дә соңга калмыйча, координация үзәге белгечләренең Халык социаль регистрына караугa мохтаҗ гражданда булганда алынган белешмәне кертүен, гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану (танудан баш тарту) турында карар проектын әзерләүне, социаль хезмәт күрсәтүгә, шул исәптән карау буенча социаль хезмәтләргә индивидуаль ихтыяҗны билгеләү буенча сораштыру анкетасын (алга таба – сораштыру анкетасы) тапшыруны һәм гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану (танудан баш тарту) турында карар проектын территориаль социаль яклау органына курьер аша кертүне оештыра;

караугa мохтаҗ граждан (аның законлы вәкиле) тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза бирелгән көннән сигез эш көненнән дә соңга калмыйча, координация үзәге белгечләренең караугa мохтаҗ гражданга социаль хезмәт күрсәтү формаларын, озак вакыт карауның социаль пакетына кертелә торган карау буенча социаль хезмәтләр һәм башка социаль хезмәтләрне сайлап алуны үткәрүен, социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасы һәм аңа өстәмәләр проектын әзерләү, социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасы һәм аңа өстәмәләр проектын курьер аша территориаль социаль яклау органына кертүне оештыра.

5.4. Территориаль социаль яклау органы бу Регламентның 5.3 пунктында каралган, координация үзәге тарафыннан тапшырылган документлар нигезендә социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге законнар белән билгеләнгән срокларда һәм тәртиптә гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану (танудан баш тарту) турында карар кабул итә, социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасына һәм аның өстәмәсенә (социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасына өстәмә караугa мохтаҗ булуның өч дәрәҗәсеннән берсен билгеләгәндә рәсмиләштерелә) имза куя.»;

VI бүлек исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«VI. Социаль хезмәткәр (карау буенча ярдәмче) һәм караугa мохтаҗ гражданның сәламәтлеген системалы күзәтү буенча медицина оешмасының территориаль участогы шәфкать туташы, участок табибы (фельдшер) арасында ведомствоара хезмәттәшлек тәртибе һәм формалары»;

6.1 пунктның беренче абзацында «социаль хезмәткәр» сүзләреннән соң «(карау буенча ярдәмче)» сүзләрен өстәргә;

6.2 пунктта:

беренче абзацта «социаль хезмәткәр» сүзләреннән соң «(карау буенча ярдәмче)» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле 6.3 пункт өстәргә:

«6.3. Координация үзәге Халыкны социаль регистры аша медицина оешмасының яңартылган белешмәсен алган көннән бер эш көне эчендә гражданның социаль хезмәт күрсәтүгә, шул исәптән карау буенча социаль хезмәтләргә индивидуаль ихтыяҗын кабат билгеләүне гамәлгә ашыра.»;

VIII бүлек исемендә «Чит кеше каравына» сүзләрен «Караугa» сүзенә алмаштырырга;

8.1 пунктның беренче абзацында «чит кеше каравына» сүзләрен «карауга» сүзенә алмаштырырга;

8.2 пунктта «чит кеше каравына» сүзләрен «карауга» сүзенә алмаштырырга;

IX бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IX. Карауга мохтаҗ гражданга Татарстан Республикасында бирелә торган озак вакыт карауның социаль пакеты турында һәм аны бирү тәртибе турында мәгълүмат бирү тәртибе

9.1. Карауга мохтаҗ гражданга Татарстан Республикасында бирелә торган озак вакыт карауның социаль пакеты турында һәм аны бирү тәртибе турында мәгълүмат бирү түбәндәгеләр тарафыннан гамәлгә ашырыла:

координация үзәге;

территориаль социаль яклау органнары тарафыннан – «Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү» дәүләт хезмәте күрсәткәндә;

социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан – социаль хезмәт күрсәтүгә кабул иткәндә;

комплекслы үзәкләр тарафыннан – йорт буйлап (фатирлар буенча) йөргәндә өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга керүне гамәлгә ашырганда;

өлкән яшьтәге кешеләргә стационар ярдәм күрсәтүче медицина оешмалары, өлкән яшьтәге кешеләргә беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүче медицина оешмалары тарафыннан – өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидлар (аларның законлы вәкилләре) медицина хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткәндә; карауга мохтаҗ гражданнарны ачыклаганда; өйдә медицина хезмәтләре күрсәткәндә;

Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге тарафыннан – карауга мохтаҗ гражданнарны ачыклаганда;

медик-социаль экспертиза буенча федераль учреждениеләр тарафыннан – медик-социаль экспертиза узучылар арасыннан карауга мохтаҗ гражданнарны ачыклаганда.

9.2. Координация үзәге Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, «Татарстан Республикасы буенча Медик-социаль экспертиза баш бюросы» федераль казна учреждениесенә, Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлегенә Татарстан Республикасында социаль пакет бирү тәртибе, социаль пакет бирүне җайга сала торган норматив хокукый актлар, территориаль социаль яклау органнары һәм халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре адреслары турында мәгълүмат, аларның ведомство буйсынуындагы учреждениеләр (филиаллар, бюролар) тарафыннан клиентлар арасында мәгълүмати кампания үткәрүне оештыру өчен мәгълүмати буклетлар җибәрә.»;

X бүлек үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин